ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.11.2022 г. Казань № 702-28/т-2022

2023 елга «Чаллы» руда булмаган материаллар житештерү берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте гамәлгә ашыра торган җирле элемтәдә елга транспортында пассажирлар йөртүгә максималь дәрәҗәдә чик тарифлар билгеләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2022 елның 14 декабрендәге 43-ПР номерлы идарә утырышы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасы нигезендә «Чаллы» руда булмаган материаллар житештерү берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте гамәлгә ашыра торган җирле элемтәдә елга транспортында пассажирлар йөртүгә максималь дәрәҗәдә чик тарифлар билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Чаллы» руда булмаган материаллар житештерү берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте гамәлгә ашыра торган җирле элемтәдә елга транспортында пассажирлар йөртүгә максималь дәрәҗәдә чик тарифлар билгеләү турында» 26.04.2013 №7-11/т карарын көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән максималь дәрәҗәдә чик тарифлар 2023 елның 1 гыйнварыннан 2023 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
14.12.2022 № 702-28/т-2022
карарына кушымта

«Чаллы» руда булмаган материаллар җитештерү берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте гамәлгә ашыра торган җирле элемтәдә елга транспортында пассажирлар йөртүгә максималь дәрәҗәдә чик тарифлар

(сум, өстәмә хак салымыннан башка)

| Бару пунктлары | Ераклык, км. | Чаллы | Вишневка | Алабуга | Түбән Кама | Сентяк | Котловка | Свиногорье | Грахань | Соколки |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Пунктлардан | | Тулы / балалар өчен | Тулы / балалар өчен | Тулы / балалар өчен | Тулы / балалар өчен | Тулы / балалар өчен | Тулы / балалар өчен | Тулы / балалар өчен | Тулы / балалар өчен | Тулы / балалар өчен |
| | | 0 | 20 | 22 | 37 | 45 | 54 | 70 | 78 | 82 |
| Чаллы | 0 | | 65/32,50 | 71/35,50 | 118/59 | 131/65,50 | 144/72 | 170/85 | 170/85 | 182/91 |
| Вишневка | 20 | 65/32,50 | | 14/7 | 60/30 | 80/40 | 111/55,50 | 136/68 | 136/68 | 144/72 |
| Алабуга | 22 | 71/35,50 | 14/7 | | 60/30 | 71/35,50 | 98/49 | 131/65,50 | 131/65,50 | 144/72 |
| Түбән Кама | 37 | 118/59 | 60/30 | 60/30 | | 51/25,50 | 60/30 | 85/42,50 | 85/42,50 | 98/49 |
| Сентяк | 45 | 131/65,50 | 80/40 | 71/35,50 | 51/25,50 | | 51/25,50 | 60/30 | 60/30 | 71/35,50 |
| Котловка | 54 | 144/72 | 111/55,50 | 98/49 | 60/30 | 51/25,50 | | 60/30 | 60/30 | 71/35,50 |
| Свиногорье | 70 | 170/85 | 136/68 | 131/65,50 | 85/42,50 | 60/30 | 60/30 | | 39/19,50 | 60/30 |
| Грахань | 78 | 170/85 | 136/68 | 131/65,50 | 85/42,50 | 60/30 | 60/30 | 39/19,50 | | 51/25,50 |
| Соколки | 82 | 182/91 | 144/72 | 144/72 | 98/49 | 71/35,50 | 71/35,50 | 60/30 | 51/25,50 | |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге